**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Мортыштамак авыл җирлегенең Боламык поселогы торак пунктында
2021 елда үзара салым кертү турында

**2002 елның 13 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлегенең Боламык авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлегенең Боламык авылы территориясендә 1 төркем инвалидлардан, ашыгыч хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортларының студентларыннан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Боламык авылы зират территориясен әйләндереп алган койманы ремонтлау өчен материаллар сатып алу.

3. Әлеге карарны Мортыштамак авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка житкерергә. Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Мортыштамак авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче И.Н.Хадиуллин